ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2026 г.Лениногорск № 299

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчаларын) гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына гаризалар кабул итү, исәпкә кую һәм балаларны кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының якынча рәвешен раслау турында» 2021елның 6 ноябрендәге под-1417/21 номерлы боерыгы белән, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (кушымта) расларга.

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм гражданнар күзәтә алырлык мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә куюны һәм җибәрү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 26 августындагы 817 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы В.С.Санатуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Г.Шәмәрданов

Г.Г.Галимова
5-24-55

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Башкарма комитетының 2026 елның 30 апрелендәге 299 номерлы карары белән расланды

# Лениногорск муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә алу һәм җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламенты

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) Лениногорск муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә алу һәм җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең (алга таба – хезмәт, муниципаль хезмәт) стандартын һәм тәртибен билгели.

Әлеге Регламентны җайга салу предметы булып гариза бирүчеләр, мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары (алга таба – Оешма) һәм «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Идарә) арасында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр тора.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: Лениногорск муниципаль районы территориясендә яшәү урыны буенча яки тору урыны буенча мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмасына укырга керүгә мохтаҗ ике айдан җиде яшькә кадәрге балаларның ата-аналары (башка законлы вәкилләре) булып торучы, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары, шулай ук Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүче чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар.

Гариза бирүче мәнфәгатьләрен гамәлдәге законнар нигезендә рәсмиләштерелгән, вәкилнең гариза бирүче исеменнән эш итү хокуклары бар икәнне раслый торган һәм вәкилнең хезмәттән файдалану хокукын гамәлгә ашыру шартларын һәм чикләрен билгели торган ышанычнамә яки шартнамә нигезендә эш итүче ышанычлы зат якларга хокуклы.

1.2.1. Оешмага укуга кабул итүнең чираттан тыш, беренче чиратта һәм өстенлекле хокукы булган балалар категорияләре:

1.2.1.1. Оешмага чираттан тыш кабул ителү хокукына ия балалар:

- «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында»26.06.1992 елгы 3132-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 19 статьясындагы 3 пункты нигезендә судьялар балалары;

- «Россия Федерациясе прокуратурасы турында»17.01.1992 елгы 2202-1 номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 5 пункты нигезендә Россия Федерациясе прокурорларының балалары;

- «Россия Федерациясе Тикшерү комитеты турында»28.12.2010 ел, № 403-ФЗ Федераль законның 35 статьясындагы 25 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Тикшерү комитеты хезмәткәрләренең балалары;

- «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарның һәм аларга тиңләштерелгән гражданнар категорияләренең балалары»Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 15.05.1991 № 1244-I Россия Федерациясе Законы нигезендә;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 9 февралендәге 65 нче номерлы «Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләрдә катнашучы һәм хокук тәртибен һәм иҗтимагый куркынычсызлыкны тәэмин итүче хәрби хезмәткәрләргә һәм федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр һәм компенсацияләр турында» карарының 14 пункты нигезендә һәлак булган (хәбәрсез югалган), вафат булган, инвалидка әйләнгән Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, җинаять-җәза системасы учреждениеләре һәм органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәте хәрби хезмәткәрләре һәм хезмәткәрләре, Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт иткән һәм полициянең махсус званиеләрен алган, Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләрдә катнашкан һәм хокук тәртибен һәм иҗтимагый куркынычсызлыкны тәэмин иткән, террористик оешмаларның һәм төркемнәрнең, аларның лидерларының һәм Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террористик акцияләр оештыруда һәм башкаруда катнашкан затларның эшчәнлеген табу һәм булдырмау буенча махсус көчләр составына керүче затлар, шулай ук Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр үткәрү буенча Берләшкән гаскәр (көч) группировкаларындагы хезмәткәрләрнең һәм хәрбиләрнең балалары;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1999 елның 25 августындагы 936 нчы номерлы «Хезмәт бурычын үтәүгә бәйле рәвештә Дагстан Республикасы территориясендә терроризмга каршы көрәштә турыдан-туры катнашкан һәм һәлак булган (хәбәрсез югалган), вафат булган, инвалидка әйләнгән хәрби хезмәткәрләрнең һәм эчке эшләр органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-башкару системасы хезмәткәрләренең гаилә әгъзаларын социаль яклау буенча өстәмә чаралар турында» карарының 1 пункты нигезендә Хезмәт бурычын үтәүгә бәйле рәвештә Дагстан Республикасы территориясендә терроризмга каршы көрәштә турыдан-туры катнашкан һәм

һәлак булган (хәбәрсез югалган), вафат булган, инвалидка әйләнгән хәрби хезмәткәрләрнең һәм эчке эшләр органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-башкару системасы хезмәткәрләренең балалары;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 12 августындагы 587 нче номерлы «Көньяк Осетия һәм Абхазия территорияләрендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының иминлеген тәэмин итү һәм саклау бурычларына үтәүдә катнашкан һәм һәлак булган (хәбәрсез югалган), вафат булган, инвалидка әйләнгән хәрби хезмәткәрләрнең һәм федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең балалары;

- махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар, мобилизация буенча Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затнар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучылар, махсус хәрби операция барышында ирекле рәвештә хәрби бурыч башкаручылар, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре, шулай ук алда күрсәтелгән категорияләрдәге, махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләрендәге балалар.

1.2.1.2. Оешмага беренче чиратта кабул ителү хокукына ия балалар:

- 1992 елның 2 октябрендәге 1157 номерлы «Инвалидларга дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Россия Федерациясе Президенты Указының 1 пункты нигезендә инвалид балалар һәм ата-анасының берсе инвалид булган балалар;

- 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы «Күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» Россия Федерациясе Президенты Указының 6 пункты нигезендә күп балалы гаиләләрдән булган балалар;

- 2011 елның 7 февралендәге 3-ФЗ номерлы «Полиция турында» федераль законның 46 статьясындагы 6 өлеше нигезендә:

1) полиция хезмәткәре балалары;

2) хезмәт вазифаларын үтәгәндә имгәнү яки сәламәтлегенә башка төрле зыян килү нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) полиция хезмәткәре балалары;

3) полициядә хезмәт итү чорында барлыкка килгән авыру нәтиҗәсендә вафат булган полиция хезмәткәре балалары;

4) хезмәт вазифаларын үтәгәндә имгәнү яки сәламәтлегенә башка төрле зыян килү нәтиҗәсендә полиция хезмәтеннән азат ителгән яки полициядә алга таба хезмәт итү мөмкинлеге булмаган Россия Федерациясе гражданины балалары;

5) хезмәт вазифаларын үтәгәндә имгәнү яки сәламәтлегенә башка төрле зыян килү нәтиҗәсендә полиция хезмәтеннән киткәннән соң яки полициядә хезмәт вазифаларын үтәгәндә барлыкка килгән, полициядә алга таба хезмәт

итү мөмкинлеге бирмәгән авыру нәтиҗәсендә бер ел эчендә вафат булган Россия Федерациясе гражданины балалары;

6) 1-5 пунктларда күрсәтелгән полиция хезмәткәре, Россия Федерациясе гражданины тәрбиясендәге (тәрбиясендә булган) балалар;

- 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» федераль законның 19 статьясындагы 6 пункты нигезендә гаиләләренең яшәү урыны буенча хәрби хезмәткәрләр балалары;

- махсус исемнәр алган һәм җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнарында, Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең федераль янгынга каршы хезмәтендә һәм Россия Федерациясе таможня органнарында хезмәт итүче, шул исәптән хезмәт вазифаларын үтәүгә бәйле рәвештә имгәнү яки сәламәтлеккә башка төрле зыян килү нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) хезмәткәрләрнең; хезмәт вазифаларын башкаруга бәйле рәвештә алынган һәм алга таба хезмәт итү мөмкинлеген калдырмый торган имгәнү яки сәламәтлеккә башка төрле зыян килү нәтиҗәсендә хезмәттән чыгарылган; хезмәт вазифаларын башкаруга бәйле рәвештә алынган һәм алга таба хезмәт итү мөмкинлеген калдырмый торган имгәнү яки сәламәтлеккә башка төрле зыян килү нәтиҗәсендә яки хезмәт итү вакытында алынган һәм алга таба хезмәт итү мөмкинлеген калдырмый торган авыру нәтиҗәсендә хезмәттән чыгарылганнан соң бер ел эчендә вафат булган хезмәткәрләрнең балалары; 2012 елның 30 декабрендәге 283-ФЗ номерлы «Кайбер федераль башкарма хакимият органнарындагы хезмәткәрләргә социаль гарантияләр һәм Россия Федерациясе закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль законның 3 статьясы нигезендә хезмәткәр – Россия Федерациясе гражданины тәрбиясендә торучы (булган) балалар;

Бала, шул исәптән уллыкка (кызлыкка) алынган яки гаиләдә опекага яки попечительлеккә алынган бала, тәрбиягә алган гаиләне яисә, Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган очракларда, патронат гаиләне дә кертеп, үзенең абыйсы һәм (яки) апасы (бертуган һәм бертуган булмаган, уллыкка (кызлыкка) алынган), опекуннары (попечительләре) әлеге баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) булып торган балалар яки ата-анасы (законлы вәкилләре) әлеге баланың опекуннары (попечительләе) булып торган балалар укый торган дәүләт яисә муниципаль мәгариф оешмасына төп гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул ителүгә өстенлекле хокукка ия

Федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив-хокукый актларында каралмаган башка нигезләр буенча лейготалар бирү рөхсәт ителми.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат бирү:

1.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат түбәндәге очракларда урнаштырыла:

1) мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен идарә биналарында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре биналарында

урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат булган мәгълүмат стендларында;

2) Идарәнең рәсми сайтында (edu.tatar.ru);

3) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал);

4) Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы);

5) «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru) (алга таба – Республика реестры).

1.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча консультацияләр түбәндәгечә бирелә:

1) Бердәм порталда, Республика порталында интерактив формада;

2) Идарәдә:

- телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

- язмача (шул исәптән электрон документ форматында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон формада электрон почта аша;

3) телдән мөрәҗәгать иткәндә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрдә – шәхсән яки телефон аша.

1.3.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында, Республика реестрындагя белешмәләргә нигезләнеп, Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган мәгълүмат гариза бирүчегә бушлай бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты һәм тәртибе турындагы мәгълүматтан файдалану гариза бирүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән гариза бирүченең техник чараларына урнаштыру гариза бирүчедән акча алуны, аның теркәлүен яки авторизация узуын яисә шәхси мәгълүматлар бирүен күз алдында тотучы программа тәэминатының хокукый иясе белән лицензияле яки башка килешү төзүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча башкарыла.

1.3.4. Гариза бирүче шәхсән яки телефон аша телдән мөрәҗәгать иткәндә, Идарәнең, Идарә бүлекләренең урнашкан урыны (адресы, эш графигы, белешмә телефоннары) турында; муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында; гариза бирү ысуллары һәм вакытлары турында; муниципаль хезмәт күрсәтелә торган гражданнар категорияләре турында; муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләрен җайга сала торган норматив хокукый актлар турында; муниципаль хезмәт күрсәтү турындагя гаризаны карап тикшерү өчен кирәкле документлар исемлеге турында; гаризаны кабул итү һәм теркәү вакытлары турында; муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында; муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүматның рәсми сайтта урнашкан урыны турында; Идарәдәге вазифаи затларның гамәлләренә яки гамәл кылмавына карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелергә мөмкин.

Язма мөрәҗәгать буенча, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы булган Идарә бүлеге вазифаи затлары гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен һәм Регламентның әлеге пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне язма формада деталь рәвештә аңлаталар, мөрәҗәгать теркәлгән көннән башлап ун эш көне эчендә гариза бирүчегә җавап җибәрәләр. Җаваплар мөрәҗәгать телендә бирелә. Мөрәҗәгать телендә җавап бирә алмаган очракта, Татарстан Республикасының дәүләт телләре кулланыла.

1.3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Идарәнең рәсми сайтында һәм Идарәдә гариза бирүчеләр белән эшләү өчен каралган бүлмәләрдәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

Мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Идарәнең рәсми сайтында урнаштырыла торган мәгълүмат Регламентның 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы муниципаль хезмәт турында белешмәләрне, Идарәнең урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш вакыты турындагы, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаларны кабул итү графигы хакындагы мәгълүматларны үз эченә ала.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) Идарәнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, Республика реестрында урнаштырылган.

Гамәлдәге редакциядәге Регламент тексты Идарәнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, Республика реестрында урнаштырылырга тиеш.

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- хезмәт – мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә балаларны исәпкә кую һәм җибәрү;

- гариза бирүче – гариза белән мөрәҗәгать итүче зат;

- гариза – 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 2 статьясындагы 3 пункты нигезендә бирелгән, Регламентта каралган теләсә нинди ысул белән җибәрелгән хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать;

- Оешма – мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гшиәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмасы;

- Идарә – «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәгариф өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыра торган җирле үзидарә органы;

- Вәкаләтле хезмәткәр – муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы зат итеп билгеләнгән Идарә хезмәткәре;

- Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасы администраторы – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының вәкаләтле хезмәткәре;

- техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең аларны кертү өчен нигез булып торган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яки арифметик яки шуңа охшаш хата);

- идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмат-технология хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы;

- ВЭХС – ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы;

- федераль дәүләт мәгълүмат системасы – мәгълүмат хезмәттәшлегендә катнашучıларның (гариза бирүче гражданнарның һәм башкарма хакимият органнарындагы һәм җирле үзидарә органнарындагы вазифаи затларның) дәүләт мәгълүмат системаларында һәм башка мәгълүмат системаларында булган мәгълүматтан рөхсәт белән файдалануын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

- күпфункцияле үзәк – «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе;

- күпфункцияле үзәкнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы – Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы;

- Электрон балалар бакчасы АМС – «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы.

## II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

2.1. Муниципаль хезмәтнең атамасы – мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм җибәрү.

2.2. Муниципаль хезмәтне турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы исеме.

Муниципаль хезмәтне Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе күрсәтә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазифаи затлар булып Идарә хезмәткәрләре тора.

Идарәнең урнашкан урыны, халыкны кабул итү сәгатьләре, белешмә телефоннары, рәсми сайты адреслары турындагы мәгълүмат Регламентның 1 нче номерлы кушымтасында күрсәтелгән.

2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы.

2.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

- исәпкә кую өлешендә – гаризага «теркәлгән» статусын бирү яки, нигезләп, гаризага «теркәлгән» статусын бирүне кире кагу турында хәбәр итү;

- балаларны Оешмага җибәрү өлешендә – гаризага «җибәрелгән» статусын бирү.

Гариза бирүчегә Бердәм портал, Республика порталы аша электрон рәвештә мәгълүмат бирелә:

1) Оешмага җибәрү һәм кабул итү өчен гаризалар турында (аерым номер һәм гариза бирү датасы);

2) гаризаларны эшкәртүнең статусы турында, аларны үзгәртүнең нигезләре һәм аларга бирелгән аңлатмалар турында;

3) Оешмада урын бирүнең тәртибе турында;

4) Оешмада урын бирү турында;

5) баланы Оешмага кабул итү турында.

2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы:

1) гаризаны кабул итү өлешендә – гариза килгән вакыттан алып бер эш көне эчендә;

2) исәпкә кую өлешендә – гариза килгән вакыттан алып биш эş көне эчендә;

3) балаларны Оешмага җибәрү өлешендә – Оешмага җибәрүне көтү вакыты муниципаль хезмәт күрсәтү вакытына керми.

2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат гаризага Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында тиешле статус бирелгән көнне гариза бирүченең Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетына электрон рәвештә җибәрелә.

2.4.2. Гамәлдәге законнар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору каралмаган.

2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәк булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиеш документларның, шулай ук муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу, шул исәптән электрон рәвештә алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) гариза бирүченең шәхесен ачыклый торган документ;

2) гариза:

- кәгазь чыганактагы документ рәвешендә (Регламентның 2 номерлы кушымтасы);

- Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (интерактив формага тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла);

3) психологик-медицина-педагогика комиссиясе бәяләмәсе (кирәк булганда);

4) сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемдә белем алуга ихтыяҗны раслый торган документ (кирәк булганда).

Исәпкә куйганда, баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) түбәндәгеләрне күрсәтергә хокуклы:

- опека билгеләүне раслый торган документ (кирәк булганда);

- аерым категориядәге гражданнарга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итүнең махсус чараларына хокуклар (гарантияләр) булуны раслый торган документ (кирәк булганда);

- Россия Федерациясе территориясендә бирелгән бала туу турында таныклык.

Чит ил гражданнары яки ватандашлыгы булмаган затлар булган баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) өстәмә рәвештә баланың шәхесен таныклый торган документ(лар)ны һәм баланың хокукларын тәкъдим итүнең законлылыгын раслый торган документ(лар)ны, шулай ук гариза бирүченең Россия Федерациясендә булу хокукын раслый торган документны күрсәтәләр. Чит ил гражданнары һәм ватандашлыгы булмаган барлык документларны рус телендә яки рус теленә тәүге чыганактан алынган расланган тәрҗемә белән тәкъдим итәләр.

Исәпкә кую өчен баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) тарафыннан гаризада түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

2) баланың туган көне;

3) бала туу турында таныклык реквизитлары;

4) баланың яшәү урыны (тору урыны, фактта яшәү урыны) адресы;

5) баланың ата-анасының (законлы вәкилләренең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

6) баланың ата-анасының (законлы вәкиленең) шәхесен таныклаучы документның реквизитлары;

7) опека билгеләүне раслый торган документның реквизитлары (булган очракта);

8) баланың ата-анасының (законлы вәкилләренең) электрон почта адресы, телефон номеры (булган очракта);

9) белем алу телен, Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган телен, шул исәптән туган тел буларак рус телен сайлау турында;

10) баланы мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган гомуми белем бирү программасы буенча укытуга ихтыяҗ турында һәм инвалид баланы

инвалидны тернәкләндерү буенча аерым программа (булган очракта) нигезендә укытуны һәм тәрбияләүне оештыру өчен махсус шартлар тудыру турында;

11) мәктәпкәчә төркемнең юнәлеше турында;

12) баланың мәктәпкәчә оешмадагы режимы турында;

13) Оешмага кабул ителергә теләгән көн турында.

Исәпкә кую турында гаризада баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) тарафыннан өстәмә рәвештә кабул итү өчен сайланган Оешмалар турында белешмәләр һәм гражданнарның аерым категорияләренең һәм аларның гаиләләренең махсус ярдәм чараларына (гарантияләргә) хокукы булу турында белешмәләр (кирәк булганда) күрсәтелә.

Баланы кабул итү өчен ата-анасы (законлы вәкиле) тарафыннан сайланган Оешмада баланың бертуган һәм өлешчә бертуган абый-энеләре яки апа-сеңелләре булган очракта, аның ата-анасы (законлы вәкилләре) исәпкә кую турында гаризада өстәмә рәвештә абый-энеләренең, апа-сеңелләренең фамилияләрен, исемнәрен, аталарының исемнәрен (соңгысы – булган очракта) күрсәтәләр.

2.5.3. Гариза һәм исәпкә кую өчен кулланыла торган документларны гариза бирүче түбәндәге ысулларның берсе белән тәкъдим итәргә (җибәрергә) хокуклы:

1) Республика порталы, Бердәм портал аша электрон формада;

2) Идарәгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә кәгазь чыганакларда;

3) төзелгән Килешү нигезендә, КФҮ аша кәгазь чыганакларда.

Гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы, Бердәм портал аша җибәргәндә физик затлар гаризага гади электрон имза куялар.

Гади электрон имза алу өчен гариза бирүчегә Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук исәп язуын стандарттан түбән булмаган дәрәҗәдә расларга кирәк.https://internet.garant.ru/document/redirect/12184522/52

Имза төренә карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 25 июнендәге 634 нче номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрдән файдалану өчен мөрәҗәгать иткәндә куллану рөхсәт ителгән электрон имза төрләре турында»гы карары нигезендә билгеләнә.

Кабул итү турында гариза муниципаль хезмәтне гамәлгә ашыру кысаларында Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасы аша юллама алынган Оешмага кәгазь чыганакта бирелә.

2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук аларны мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан алу, шул исәптән электрон формада алу ысуллары, аларны бирү тәртибе; карамагында әлеге документлар булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма.

2.6.1. Гариза бирүче тарафыннан гаризага кертелгән, Бердәм портал, Республика порталы аша җибәрелә торган бала турындагы белешмәләр (баланы фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне, туу турында таныклык реквизитлары буенча тәңгәлләштерү) гражданлык хәле актларын теркәү органнары белән ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында автомат режимда раслана.

Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында (кирәк булганда) түбәндәгеләрне алырга мөмкин:

- Россия Федерациясе территориясендә бирелгән бала туу турында таныклык (гражданлык хәле актларын теркәү органнары тарафыннан бирелә);

- опека билгеләүне раслый торган документ (опека органнары тарафынән бирелә);

- баланы яшәү урыны яки беркетелгән территориядә тору урыны буенча теркәү турында таныклык (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары тарафыннан бирелә);

2.6.2. Гариза бирүче ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек ярдәмендә алына торган документларны мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы.

Гариза бирүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмау муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигез була алмый.

Гариза бирүче, гаризаны тапшырганда, 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларны (белешмәләрне) электрон формада яки мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән расланган электрон документлар формасында тапшырырга хокуклы.

2.6.3. Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагындагя оешмаларда булган документларны таләп итү тыела.

Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган мәгълүматларны үз эченә алган документларның гариза бирүче тарафыннан тапшырылмавы гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигез була алмый.

2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге:

2.7.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләр:

- гариза бирүче тарафыннан мәҗбүри тапшырылырга тиешле, Регламентның 2.5.1 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган җыелмасын тапшыру;

- дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы мәгълүматларны, эчтәлеген төгәл аңларга мөмкинлек бирми торган килешенмәгән төзәтүләрне, җитди бозуларны үз эченә алган документлар тапшыру;

- гариза бирүче исеменнән бирелә торган гаризаның (мөрәҗәгатьнең) моңа вәкаләте булмаган зат тарафыннан тапшырылуы;

- гариза бирүче тарафыннан шәхесне таныклый торган документны тапшырмау яки гамәлдә булу вакыты узган шәхесне таныклый торган документны яки гамәлдә булмаган шәхесне таныклый торган документны тапшыру;

- гариза бирүченең гариза бирүчегә кирәкле хезмәтне күрсәтми торган җирле үзидарә органына, җирле үзидарә органына буйсына торган оешмага муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүе;

- Регламент нигезендә муниципаль хезмәттән файдаланучы булып тормаган затның муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүе;

- интерактив мөрәҗәгать формасында мәҗбүри тутырылырга тиешле юлларны дөрес тутырмау;

- электрон формадагы гаризаның (мөрәҗәгатьнең) һәм башка документларның, гамәлдәге законнарны бозып, электрон имзадан файдаланып имзалануы;

- электрон документларның аларны тапшыру форматларына куелган таләпләргә туры килмәве һәм (яки) укылмавы;

- Республика порталында, Бердәм порталда гаризада күрсәтелгән, бала турында бердәй мәгълүматлар булган башка гариза булу.

2.7.2. Муниципаль хезмәтне алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге тулы.

2.7.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итүне кире кагу турындагы карар гариза бирүчене кабул иткән вакытта да, шулай ук Идарәдәге җаваплы вазифаи зат тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны (белешмәләрне) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша алганнан соң да, гаризаны теркәгән көннән алып, алты эш көненнән артмаган вакытта кабул ителергә мөмкин.

2.7.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты һәм тәртибе турында Бердәм порталдагы, Республика порталындагя мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм башка документларны кабул итүне кире кагу тыела.

2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.8.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләр:

- баланың яше Оешмага кабул ителә торган балаларның максималь яшеннән артып китү;

- ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) муниципаль хезмәттән файдаланудан баш тартуы турында гариза;

- Оешмада буш урыннар булмау;

- балага медицина ягыннан Оешмага йөрү ярамавы.

2.8.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләр исемлеге тулы булып санала.

2.8.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турындагы карар, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, өлеге Регламентның 9 нчы номерлы кушымтасында бирелгән форма буенча әзерләнә, билгеләнгән тәртиптә Идарәнең вәкаләтле вазифаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар кабул ителгән көнне гариза бирүченең Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

2.8.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Республика порталында бастырылган мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу тыела.

Оешмада урын булмаган очракта, баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) аны башка Оешмага урнаштыру мәсьәләсен хәл итү өчен турыдан-туры Идарәгә мөрәҗәгать итә.

2.8.6. Гариза бирүче шәхси язма гариза нигезендә хезмәт күрсәтүдән баш тартырга хокуклы.

Язмача баш тарту хезмәттән файдалану өчен кабат мөрәҗәгать итүгә комачауламый.

2.9. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре.

Муниципаль хезмәт бушлай күрсәтелә.

2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында мәгълүмат.

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, мондый түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре.

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелүче хезмәттән файдалану турында гариза биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты.

2.12.1. Муниципаль хезмәттән файдалануга гариза бирү өчен Идарәгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә чиратта көтү 15 минуттан артмаска тиеш.

2.12.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.13. Мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәттән һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәттән

файдалану турындагы гаризасын, шул исәптән электрон формада, теркәү вакыты һәм тәртибе.

2.13.1. Күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүчегә гариза тапшырылган көнне теркәү номеры һәм гариза бирү көне күрсәтелгән раслама бирелә.

2.13.2. Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәрелгән очракта, гариза бирүче гариза биргән көнне Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетында гаризаның җибәрелүен раслый торган, гаризаны теркәү номеры һәм гариза бирү көне күрсәтелгән хәбәрнамә ала.

2.13.3. Гариза бирүче Идарәгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гаризаны теркәү гариза биргән көнне башкарыла.

Гариза бирүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә – күпфункцияле үзәктән гариза һәм документлар кабул ителгән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча.

2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүматны урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидларның күрсәтелгән объектлардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүгә карата таләпләр.

2.14.1. Муниципаль хезмәт күрѕәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.

Яралтачларны кабул итү урыннары документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, информацион стендлар белән җиһазландырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү урынына инвалидларның тоткарлыксыз керүе (бүлмәгә керү-чыгу урыннарының һәм бүлмә эчендә йөрүнең уңайлылыгы) тәэмин ителә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматы инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, яралтачлар өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән урнаштырыла.

2.14.2. Инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә аларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керүен тәэмин итү максатыннан түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

1) транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

2) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре нык бозылган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

3) аларның яшәеш мөмкинлекләре чикле булуны исәпкә алып, инвалидларның хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалануын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;

4) ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-ноктала Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау;

5) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

6) махсус өйрәтелгән булуын раслый торган һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы «Озатып йөрүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында»гы әмере белән билгеләнгән формада һәм тәртиптә бирелгән документ булганда, озатып йөрүче этне кертү.

Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтелә торган объектлардан һәм әлеге пунктның 1-4 пунктчаларында күрсәтелгән, муниципаль хезmәт күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга кертелгән яки яңартылган, реконструкцияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.15. Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алу һәм аның sыйфат күрсәткечләrе, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү барышында гариза бирүченең вазифаи затлар белән аралашу саны, аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрдә 210-ФЗ номерлы федераль законның 15.1 статьясы белән каралган берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза (комплекслы мөрәҗәгать) бирү ярдәмендә муниципаль хезмәтне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә (шул исәптән тулы күләмдә), гариза бирүченең сайлавы буенча җирле үзидарәнең башкарма-оештыру органындагы теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә (экстерриториаль принцип) алу мөмкинлеге яки мөмкин булмавы.

2.15.1. Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләре:

- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бүлмәләрнең җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашуы;

- белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

- мәгълүмат стендларында, Идарәнең рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

- гаризаны электрон формада бирү мөмкинлеге;

- гариза бирүче тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәtү нәтиҗәләрен электрон формада алу мөмкинлеге;

- инвалидларга хезмәтләрдән башкалар белән тигез дәрәҗәдә файдаланырга комачаулый торган каршылыкларны узуда ярдәм итү.

2.15.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын билгели торган күрсәткечләр:

- документларны кабул итү һәм карап тикшерү вакытын үтәү;
- муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытын үтәү;
- Идарә хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;
- гариза бирүченең вазифаи затлар белән аралашу саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм порталны, Республика порталын, терминалларны кулланып бәяләргә хокуклы.

2.15.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүматны гариза бирүче Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетында алырга мөмкин.

2.15.4. Экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтелми.

2.16. Башка таләпләр, шул исәптән муниципаль хезмәттән экстерриториаль принцип буенча (муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада файдалану үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр.

2.16.1. Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәткәндә җыелма тапшыручы хакына ия:

а) Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинеттан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон документ формасында гариза бирергә;

в) электрон формада тәкъдим ителгән муниципаль хезмәт күрсәтү турында җыелмаларның барышы турында мәгълүмат алырга;

г) Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

д) Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алырга;

е) Бердәм портал, Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, алардагы вазифаи затлар, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кабул ителгән карарларга һәм башкарылган гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша Идарәнең, шулай ук андагы вазифаи затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирергә.

2.16.2. Гариза бирүчеләрне кабул итүгә язылу (алда - язылу) Бердәм портал, Республика порталы, күпфункцияле үзәкнең контакт-үзәге телефоны аша үткәрелә. Гариза бирүчегә күпфункцияле үзәктә кабул итү графигы чикләрендә теләгән датага һәм вакытка язылу хокугы бирелә. Билгеләнгән датага язылу әлеге дата башланганчы 24 сәгать кала тәмамлана. Бердәм портал, Республика порталы аша алдан язылу үткәргәндә, гариза бирүче система сораган мәгълүматларны күрсәтергә тиеш, шул исәптән:

- фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта);
- телефон номеры;
- электрон почта адресы (теләк буенча);
- теләгән кабул итү көне һәм вакыты.

Алдан язу вакытында җыелма тапшыручы белдергән мәгълүматларның, шәхси кабул итү вакытында җыелма тапшыручы тәкъдим иткән документларның, туры килмәве очрагында, алдан язу бетерелә.

Алдан язу үткәргәндә гариза тапшыручыга талон-раслауны бастыру мөмкинлеге тәэмин ителә. Әгәр җыелма тапшыручы электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук алдан язуны раслау турында мәгълүмат, кабул итү урыны, вакыты һәм датасы күрсәтелеп җибәрелә.

Алдан язу үткәргәндә җыелма тапшыручы мәҗбүри тәртиптә, билгеләнгән кабул итү вакыты үткәннән соң 15 минут узгач килмәсә, алдан язу бетереләчәген хәбәр ителә.

Гариза тапшыручы теләсә нинди вакытта алдан язудан баш тартырга хакы бар.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләү һәм аутентификацияләү үтүдән, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен кирәкле вакыт аралыгын исәпләү өчен тиешле белешмәләрне тапшырудан тыш, гариза бирүчедән башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

## III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә башкару үзенчәлекләре.

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә эшләр эзлеклелеге тасвирламасы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультацияләр бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны тутыру өлешендә ярдәм күрсәтү;

2) гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлар комплектын кабул итү һәм карап тикшерү, Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризаны теркәү;

3) мәгълүматлар алу, ведомствоара запрослар төзү һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү;

4) ведомствоара хезмәттәшлек органнары тарафыннан документларны (белешмәләрне) формалаштыру һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша җибәрү;

5) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү (Оешмага җибәрү һәм кабул итү);

6) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

7) техник хатаны төзәтү.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү.

Административ процедураны үтәүне башлау өчен мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгате нигез булып тора.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы булган вазыйфалы зат (хезмәткәр):

1) гариза бирүче Идарәгә мөрәҗәгать иткәндә – Идарәнең вәкаләтле хезмәткәре;

2) күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә – күпфункцияле үзәк хезмәткәре.

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм вакытлары турында консультация алу өчен шәхсән, телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук Бердәм порталда, Республика порталында консультация алырга хокуклы.

Идарәнең вәкаләтле хезмәткәре гариза бирүчегә, муниципаль хезмәттән файдалану өчен, документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация бирә.

Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагя мәгълүматны күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан (http://mfc16.tatarstan.ru) ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документациянең составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.2.2. Гариза бирүче Идарәгә телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм вакытлары турында Идарә сайтында консультация алырга хокуклы.

Консультацияләр бирү өчен җаваплы вазифаи зат гариза бирүчегә Регламентның 1.3.4 пункты таләпләре нигезендә мәгълүмат бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документациянең составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.3. Гариза бирүче тапшырган документлар җыелмасын кабул итү һәм карап тикшерү, Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризаны теркәү.

3.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документларны күпфункцияле үзәк яки күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны аша кабул итү.

3.3.1.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән күпфункцияле үзәккә шәхсән үзе мөрәҗәгать итә һәм Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

3.3.1.2. Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итүче хезмәткәре:

- мөрәҗәгать предметын билгели;
- гариза бирүченең шәхесен таныклый;
- документлар тапшыручы затның вәкаләтләрен тикшерә;
- документларның Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә;
- күпфункцияле үзәкнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризаның электрон формасын тутыра;
- Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кәгазь чыганакта тапшырылган очракта, аларны сканерлый;
- күпфункцияле үзәкнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан гаризаны бастырып чыгара;
- тикшерү һәм имзалау өчен гариза бирүчегә тапшыра;
- имзаланган гаризаны күпфункцияле үзәкнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасында сканерлый;
- электрон формада тапшырылган документларны яки сканерланган документларның электрон сурәтләрен күпфункцияле үзәкнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертә, электрон эш формалаштыра;
- имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның төп нөсхәләрен кире кайтара;
- гариза бирүчегә документларны кабул итү турында раслама бирә.

Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итүче хезмәткәре, техник мөмкинлек булмаганда, гариза бирүчедән гаризаны һәм документларны кәгазь чыганакта кабул итә, эш формалаштыра, документларны кабул итү турында раслама бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрергә әзер гариза һәм документлар җыелмасы.

3.3.1.3. Күпфункцияле үзәк хезмәткәре гариза бирүчедән кабул ителгән документлар җыелмасын электрон рәвештә (электрон эшләр җыелмасы составында) гариза бирүче күпфункцияле үзәкнең структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән алып бер эш көне эчендә Идарәгә җибәрә.

Техник мөмкинлек булмаганда, гаризаны һәм документлар җыелмасын (кәгазь чыганакта) Идарәгә билгеләнгән вакытта курьер хезмәте аша җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарәгә электрон хезмәттәшлек ярдәмендә җибәрелгән гариза һәм документлар җыелмасы (электрон эш) яки Идарәгә курьер хезмәте ярдәмендә җибәрелгән гариза һәм документлар җътелмасы (кәгазь чыганакта).

3.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документларны Бердәм портал, Республика порталы аша электрон формада кабул итү.

3.3.2.1. Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша электрон формада бирү өчен гариза бирүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

- Бердәм порталда, Республика порталында авторизация үтә;
- Бердәм порталда, Республика порталында электрон гариза формасын ача;
- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгын раслый (электрон гариза формасында тиешле тамганы билгели);
- муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган мәгълүматларны үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;
- электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу, килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга куя);
- хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга куя);
- тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);
- электрон гариза 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә (гади электрон имза һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;
- электрон гаризаны җибәрү турында хәбәрнамә ала.

Электрон гариза электрон гаризага кертелгән бала турында мәгълүматларның дөреслеген автомат рәвештә тикшерү (баланың туу турында таныклыгындагы мәгълүматларны Гражданлык хәле актларын теркәү органнары аша тәңгәлләштерү) башкарыла торган Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасына керә. Әгәр дә мәгълүматлар дөрес булса, гаризага «Теркәлгән» статусы бирелә.

Әгәр дә мәгълүматлар дөрес түгел яки юк булса, гаризага «Документларны раслау» статусы бирелә. Документларны раслау өчен гариза бирүче Идарәгә яки КФҮгә мөрәҗәгать итә. Документларны гариза бирүче тарафыннан расланганнан соң, бер эш көне эчендә гаризага АЭББ АМСда «Теркәлгән» статусы бирелә. Гариза бирүче КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә - гаризаны һәм документларны кабул иткән көннән алып биш эш көненнән соң.

Әгәр дә гариза бирүче гаризада баланы Оешмага читенче, беренче чиратта, өстенлекле рәвештә кертергә хокуклылыгын яки сәламәтлеге буенча ихтыяҗлылыгын (компенсацияләүче, комбинирланган һәм сәламәтләндерү

юнәлеше төркемнәренә кертергә ихтыяҗлылык) күрсәтсә, аның гаризасына АЭББ АМСда «Документларны раслау» статусы бирелә. Раслау өчен гариза бирүче Идарәгә ташламаны (әти-әни(ләр)нең (баланың кануни вәкил(ләр)е) эш урыныннан справкасы, сәламәтлеге буенча ихтыяҗлылыкны раслаучы справка) раслаучы документларның төп нөсхәләрен тапшыра.

Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән ташламалар исемлеге, дәүләт органына яки әлеге документлар (белешмәләр) булган оешмага запрос ясау ярдәмендә автомат рәвештә раслана.

Процедураның нәтиҗәсе: баланы исәпкә кую – гаризага Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында «Теркәлгән» статусы бирү.

3.3.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Идарәгә документлар кабул итү һәм карап тикшерү.

3.3.3.1. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән Идарәгә шәхси мөрәҗәгать итүе административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

3.3.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы Идарә хезмәткәре:

- документлар тапшыручы затның вәкаләтләрен тикшерә;
- мөрәҗәгать предметын билгели;
- документларның Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә;
- гариза бирүченең гаризаны (Регламентның 2-6 нчы номерлы кушымталары) һәм шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкны (Регламентның 7 нче номерлы кушымтасы) тутыруын тикшерә;
- Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризаның электрон формасын тутыра;
- Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны кәгазьдә тапшырганда, тапшырылган документларның күчермәсен ясый;
- Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризага «Теркәлгән» статусы бирә;
- кәгазь документларның төп нөсхәләрен кире кайтара;
- гариза бирүчегә документларны кабул итү турында раслама бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: баланы исәпкә кую – гаризага Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында «Теркәлгән» статусы бирү.

3.3.4. Күпфункцияле үзәк аша килгән документлар җыелмасын карап тикшерү.

3.3.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документлар килү административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

Документлар карап тикшерүгә кергәннән соң вәкаләтле хезмәткәр түбәндәгеләрне башкара:

а) документ күчермәләре һәм документлар реестры күпфункцияле үзәктән электрон рәвештә (электрон эш җыелмалары составында) бирелгән очракта, документлар реестрын тапшырылган документлар белән чагыштыра;

б) кергән электрон эшләрне, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан тапшырылган электрон формадагы документларны һәм документларның электрон сурәтләрен өйрәнә;

в) документлар җыелмасының тулылыгын, электрон сурәтләренең укылышын тикшерә;

г) гариза бирүченең гаризасындагы белешмәләрне Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертә, гаризага Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында «теркәлгән» статусын бирә, бу гариза бирүченең Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетында чагыла.

3.3.4.2. Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу турында карар кабул итә.

Документларны кабул итүне кире кагу турында карар, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп (муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләр мондый документларга карата билгеләнгән таләпләр бозылу белән бәйле булган очракта, документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрдә тапшырылмаган, дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләрне үз эченә алган, билгеләнгән таләпләрне бозып тутырылган документлар (мәгълүмат, белешмәләр) исемнәре турында мәгълүмат булырга тиеш), Регламентның 8 нче номерлы кушымтасындагя форма буенча рәсмиләштерелә, электрон документлар әйләнеше системасында теркәлә һәм вәкаләтле вазифаи затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасын файдаланып имзалана һәм гариза кергәннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча күпфункцияле үзәккә һәм гариза бирүченең Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның гамәлдә булу шартларының үтәлмәве ачыкланган очракта, хәбәрнамәдә аны кабул итү өчен нигез булып торган 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясы пунктлары булырга тиеш.

3.3.4.3. Регламентның 3.3.3.2, 3.3.4.1 пунктларында күрсәтелгән процедуралар, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарылырга мөмкин.

3.3.4.4. Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза карап тикшерүгә кергән көннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баланы исәпкә кую – гаризага Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында

«теркәлгән» статусын бирү яки документларны кабул итүне кире кагу турында хәбәр итү.

3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.1. Административ процедураны башкаруга вәкаләтле вазифаи затның (хезмәткәрнең) документларны кабул итү өчен җаваплы вазифаи заттан (хезмәткәрдән) гариза бирүчедән кабул ителгән документларны алуы административ процедураны үти башлау өчен нигез булып тора.

Ведомствоара запрослар җибәрү өчен җаваплы вазифаи зат административ процедураны башкару өчен җаваплы вазифаи зат (хезмәткәр) булып тора.

Гаризаны теркәгәннән соң ведомствоара запрослар төзү һәм җибәрү өчен җаваплы вазифаи зат электрон формада запрослар төзи һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә (техник мөмкинлек булмаганда – башка ысуллар белән) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган органнарга юллый.

Запроста дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуында булган оешмалар карамагында булган, муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәк булган белешмәләрнең исемлеге күрсәтелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза карап тикшерүгә кабул ителгәннән соң өч көннән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: хакимият органнарына һәм (яки) хакимият органнары карамагындагы оешмаларга җибәрелгән мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә мәгълүмат белән тәэмин итә торган оешма белгечләре соратыла торган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәрнамә (алга таба – кире кагу турында хәбәрнамә) юллыйлар.

Әгәр ведомствоара запроска җавап әзерләүнең һәм җибәрүнең башка вакыты федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса, әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар документ һәм мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага ведомствоара запрос кергән көннән соң ун көн эчендә башкарыла.

Ведомствоара запрослар төзү һәм җибәрү өчен җаваплы вазифаи зат ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша муниципаль хезмәт күрсәтү өвен кирәкле документларны (белешмәләрне) ала яки, документ һәм (яки) мәгълүмат булмаганда, кире кагу турында хәбәрнамә ала.

3.4.3. Регламентның 3.4.1, 3.4.2 пунктларында күрсәтелгән процедуралар дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын файдаланып, автомат режимда,

шул исәптән гаризаны Регламентның 2.13 пункты нигезендә теркәү вакытыннан алып башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ведомствоара запрослар төзү һәм җибәрү өчен җаваплы вазифаи затка җибәрелгән документлар (белешмәләр) яки кире кагу турында хәбәрнамә.

Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь вакыты ун эш көнен тәшкил итә.

3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. Оешмага җибәрү.

3.5.1.1. Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында «теркәлгән» статусындагы гаризалар булу һәм Оешмада буш урыннар булу административ процедураны үти башлау өчен нигез булып тора.

Буш урыннар турындагы мәгълүматны Оешмалар җитәкчеләре яңа уку елына урыннар бүлендереп биргәндә һәм уку елы эчендә урыннар бушанганда Идарәгә бирәләр.

Оешмаларга чираттагы уку елына балалар туплау (төп комплектлау) тиешле яшь төркемнәре буенча расланган буш урыннар саны һәм аларда алып барыла торган мәктәпкәчә белем бирү программасы нигезендә 1 июннән 31 августка кадәр гамәлгә ашырыла.

Оешмаларда тәрбияләнүчеләрнең китүе, яңа мәктәпкәчә урыннар кертелеп тору очракларында, 1 сентябрдән 30 апрельгә кадәр оешмаларны әлеге Регламентның 3.5 пункты белән билгеләнгән юллама тәртибе буенча тулыландыру үткәреле.

Туплау нәтиҗәләре турында мәгълүмат гражданнарга дәүләт хезмәтләре бердәм порталы (gosuslugi.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (uslugi.tatarstan.ru) аша бирелә.

Оешмаларны туплаганда гражданнарның гаризалары Вәкаләтле хезмәткәрләр тарафыннан биш эш көненнән дә артыграк булмаган вакыт эчендә эшкәртелергә мөмкин.

Гариза бирүченең чираты килеп җиткәндә һәм теләгән Оешмада тиешле яшь төркемендә урын булганда, Вәкаләтле хезмәткәр баланы Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасы аша Оешмага җибәрә. Гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелде» статусы бирелә.

Процедура нәтиҗәсе: Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелде» статусын бирү.

3.5.1.2. Гариза бирүче «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелде» статусы бирелгәннән соң 30 календарь көн эчендә баланы кабул итүне раслау өчен оешмага мөрәҗәгать итә.

Оешма җитәкчесе гариза бирүче баланы кабул итү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән вакыттан алып бер эш көне эчендә Электрон балалар

бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризага «килешү төзү» статусын бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән вакыттан алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гаризага Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында «килешү төзү» статусы бирү.

3.5.1.3. Гариза бирүчене бала җибәрелгән Оешма канәгатьләндермәгән очракта, гариза бирүче тарафыннан әлеге Оешмага җибәрүдән баш тарту рәсмиләштерелә.

Тәкъдим ителгән Оешмага җибәрүдән баш тарту күпфункцияле үзәккә яки идарәгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә билгеләнгән тәртиптә язма рәвештә рәсмиләштерелә (Регламентның 4 нче номерлы кушымтасы).

Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризага «Теркәлгән» статусы бирелә. Әлеге вакытта теркәү датасы үзгәрми. Гариза бирүче җибәрүдән баш тарту турында мөрәҗәгать иткән көннән иртәрәк булмаган датага теләп кабул итү датасы үзгәртелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче Идарәгә мөрәҗәгать иткән вакыттан бер эш көне эчендә, гариза бирүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә – күпфункцияле үзәктән гариза һәм документлар кабул ителгән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризага «теркәлгән» статусын бирү, тәкъдим ителгән Оешмага бирелгән юлламадан баш тарту.

3.5.1.4. Гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелде» статусы бирелгәннән соң гариза бирүче Регламентның 3.5.1.2 пунктында билгеләнгән вакытта килмәгән очракта, Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризага автомат рәвештә «килмәде» статусы бирелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.5.1.2 пунктында билгеләнгән вакыт узганнан соң бер эш көне эвендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гаризага Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында «килмәде» статусы бирү.

3.5.1.5. Әгәр гариза бирүче хезмәттән файдалануны расласа, гаризага «Теркәлгән» статусы бирелә. Бу очракта теркәү датасы үзгәрми. Әгәр гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдаланудан баш тартса, гаризага «Хезмәт күрсәтү кире кагылды» статусы бирелә. Муниципаль хезмәттән файдалануны раслау яки баш тарту күпфункцияле үзәккә яки Идарәгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә язма рәвештә рәсмиләштерелә. Раслау булганда, теләп кабул итү датасы гариза бирүче муниципаль хезмәткә ихтыяҗлылыгын раслап мөрәҗәгать иткән көннән иртәрәк булмаган датага үзгәртелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче Идарәгә мөрәҗәгать иткән вакыттан бер эш көне эчендә, гариза бирүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә – күпфункцияле үзәктән гариза

һәм документлар кабул ителгән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гаризага Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында «теркәлгән» яки «хезмәт күрсәтү кире кагылды» статусы бирү.

3.5.1.6. «Килешү төзү» статусы бирелгәннән соң төп туплау вакытында гариза бирүче 31 августка кадәр оешмага килешү төзү өчен мөрәҗәгать итә.

Оешмаларны тулыландыру вакытында гариза бирүчегә килешү төзү өчен мөрәҗәгать итү сроки 10 календарь көн тәшкил итә.

Ата-аналар (законлы вәкилләр) белән килешү төзелгәннән соң Оешма җитәкчесе Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына кабул ителде» статусын бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар ата-аналар (законлы вәкилләр) белән килешү төзелгән вакыттан алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Төп туплау вакытында баланы кабул итү оешмада урын бушанганда һәм балага тулы документлар пакеты булганда гамәлгә ашырыла. Төп туплау вакытында баланы оешмага кабул итү хәзерге елның 31 августыннан соңга калдырылмый.

Процедура нәтиҗәсе: гаризага Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына кабул ителде» статусын бирү.

3.5.1.7. Гариза бирүче Регламентның 3.5.1.6 пункты белән билгеләнгән килешү төзү срокында килмәгән очракта, оешма җитәкчесе гаризага «Килмәде» статусын бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гаризага Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында «килмәде» статусы бирү.

3.5.1.8. Әгәр гариза бирүче хезмәттән файдалануны расласа, гаризага «Теркәлгән» статусы бирелә. Бу очракта теркәү датасы үзгәрми. Раслау булганда, теләп кабул итү датасы гариза бирүче муниципаль хезмәткә ихтыяҗлылыгын раслап мөрәҗәгать иткән көннән иртәрәк булмаган датага үзгәртелә.

Әгәр гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдаланудан баш тартса, гаризага «Хезмәт күрсәтү кире кагылды» статусы бирелә.

Муниципаль хезмәттән файдалануны раслау яки файдаланудан баш тарту күпфункцияле үзәккә яки Идарәгә билгеләнгән форма буенча мөрәҗәгать иткәндә язма рәвештә рәсмиләштерелә (раслау – Регламентның 4 нче номерлы кушымтасы, кире кагу – Регламентның 6 нчы номерлы кушымтасы).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче Идарәгә мөрәҗәгать иткән вакыттан бер эш көне эчендә, гариза бирүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә – күпфункцияле үзәктән гариза һәм документлар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризага Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында «теркәлгән» яки «хезмәт күрсәтү кире кагылды» статусы бирү.

3.5.1.9. Баланы билгеле бер вакытка компенсацияләү яки сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемгә (вакытлыча, медицина бәяләмәсе яки психологик-медицина-педагогик комиссия бәяләмәсе нигезендә) юллаган очракта Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасына юлламада Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасы администраторы тарафыннан «вакытлыча кабул итү» тамгасы куела.

Гариза исәпкә куелуның беренче көне белән куелган чират буенча саклана.

Әгәр бала компенсацияләү яки сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемгә юлланган вакытта башка Оешмада йөргән булса, Оешма җитәкчесе, махсус төркемдә йөрү вакыты тәмамлану көнен күрсәтеп, баланы вакытлыча Оешмадан чыгара.

3.6. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.6.1. Теркәлгән гаризага аерым тәңгәлләштерү номеры бирелә. Гариза статусын гариза бирүче Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетында, шулай ук кабул итү сәгатьләрендә Идарәгә шәхсән яки телефон аша мөрәҗәгать итеп тикшерә ала.

3.6.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы һәм нәтиҗәсе турындагы мәгълүмат гариза статусының алышынуы турындагы хәбәрләр («теркәлде», «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына юлланды», «шартнамә төзү», «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына кабул ителде», «килмәде») рәвешендә Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетта чагыла.

Процедура, Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы һәм нәтиҗәсе турында мәгълүмат бирү.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Гаризада техник хата ачыкланган очракта, аңа аерым тәңгәлләштерү номеры бирелгәннән соң, гариза бирүче, хата булуны дәлилли торган документларны беркетеп, техник хатаны төзәтү турында тиешле гариза белән күпфункцияле үзәккә яки Идарәгә мөрәҗәгать итә.

3.7.2. Вәкаләтле хезмәткәр, ясалган хаталарны (исәпкә кую көненнән башка, баланың фамилиясендә, исемендә, атасының исемендә, туган көнендә, туу турында таныклык реквизитларында һ.б.) бетерү максатыннан,

муниципаль хезмәттән файдалануга гариза бирелгән көннән алып биш эш көне эчендә Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гражданинның гаризасына тиешле төзәтмәләр кертергә хокуклы. Бу вакыт үткәч, үзгәрешләр кертү Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасы администраторы тарафыннан вәкаләтле хезмәткәрнең соравы буенча башкарыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура, теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хатаны төзәтү турында гариза алынганнан соң, биш эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризадагһ хатаны төзәтү.

3.7.3. Гаризага аерым тәңгәлләштерү номеры бирелгәннән соң, гаризада теләнгән Оешманы алыштыру рөхсәт ителә. Гариза бирүче теләнгән Оешманы алыштыру турында гаризаны теләнгән Оешма урнашкан урындагы муниципаль мәгариф идарә органнарына яки күпфункцияле үзәккә тапшыра. Бу очракта исәпкә куюю көне саклана.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче Идарәгә мөрәҗәгать иткән вакыттан бер эш көне эчендә, гариза бирүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә – күпфункцияле үзәктән гариза һәм документлар кабул ителгән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Гариза бирүче Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетында гаризадагы теләнгән Оешманы үзгәртә ала.

Процедураның нәтиҗәсе: Электрон балалар бакчасының автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризада теләнгән Оешманы алыштыру.

## IV. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Җаваплы вазифаи затлар тарафыннан Регламент нигезләмәләренең һәм муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларның үтәлешен һәм башкарылуын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе.

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклауны һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерүне, җирле үзидарә органындагы вазифаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формаларына түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү;

2) эш башкаруны алып бару буенча билгеләнгән тәртиптә тикшерүләр уздыру;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлеше буенча билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Агымдагы контрольдә тоту максатыннан электрон мәгълүматлар базасында булган белешмәләр, хезмәт корреспонденциясе, административ процедураларны башкаручы вазифаи затлар тарафыннан телдән һәм язмача бирелгән мәгълүмат, тиешле документларны исәпкә алу журналлары һәм башка мәгълүмат кулланыла.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләр кылуны контрольдә тоту өчен җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

Административ процедураларны башкару вакытын, эзлеклелеген һәм эчтәлеген бозу очраклары һәм сәбәпләре турында вазифаи затлар муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган җитәкчесенә кичекмәстән хәбәр итәләр, шулай ук хокук бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрәләр.

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүне агымдагы контрольдә тоту җирле үзидарә органы җитәкчесенең муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыру өчен җаваплы урынбасары, муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыруны гамәлгә ашыра торган бүлек башлыгы тарафыннан башкарыла.

Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазифаи затлар исемлеге Идарәнең структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазифаи регламентлар белән билгеләнә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфаты буенча планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыру тәртибе һәм аларның кабатлану ешлыгы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тотуның тәртибе һәм формалары.

Тикшерүләр планлы (Идарәнең ярымъеллык яки еллык эш планнары нигезендә үткәрелеп торырга мөмкин) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә, муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яки заявительнең билгеле бер мөрәҗәгате буенча каралырга мөмкин.

4.3. Муниципаль хезмәт күрсәтә торган органдагы вазифаи затларның муниципаль хезмәт күрсәтү барышында алар тарафыннан кабул ителә торган карарлары һәм башкарыла (башкарылмый) торган гамәлләре өчен җаваплылыгы.

Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

Җирле үзидарә органы җитәкчесе гаризаларны вакытында карап тикшермәгән өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) Регламентның III бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Вазифаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган карарлар һәм башкарыла (башкарылмый) торган гамәлләр өчен законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан контрольдә тоту тәртибенә һәм формаларына карата таләпләрне билгели торган нигезләмәләр.

Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә Идарә эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

V. Муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук алардагя вазифаи затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәтне алучылар судка кадәр тәртиптә Идарәнең хезмәткәрләренең гамәлләрен (гамәлсезлеген), муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучыларның, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән сорауның шикаять ителү хокукына ия. Гариза бирүче түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорауын теркәү вакытын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын бозу;

3) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру яки башкару каралмаган документлар яки мәгълүмат тапшыруны яки гамәлләр кылуны таләп итү;

4) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру каралган документларны кабул итүне кире кагу;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында,

муниципаль хокукый актларда баш тарту өчен нигезләр каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

